# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кара-Елга поселогында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**9 декабрь, 2024 ел** **№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Кара-Елга поселогында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларыннан, I төркем инвалидларыннан, 18 яшькә кадәр 5 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтә һәм аннан өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокны хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; МХОда катнашучы, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

урам яктыртуны ясау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су суырту манарасын,

су саклау зонасын, су белән тәэмин итү челтәрен һәм ул тирәдәге территорияләрне карап тоту, ремонтлау, төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

коеларны ясау, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү,

җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (чистарту һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (яр буе зоналарын чистарту һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы җиһазлар, савытлар, гидрантлар һәм комплектлау материаллары сатып алу, урнаштыру, карап тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү өчен кулланыла торган сулыкларны), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау; (гидротехник корылмаларны ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту, янгын сүндерү техникасына гидротехник корылмаларга керү өчен мәйданчыкны төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техик күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү, гидротехник корылмаларны ремонтлау, төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре);

һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (мемориаль корылмалар (һәйкәл, обелиск, мемориаль такталар) сатып алу, төзү, ремонтлау, урнаштыру, карап тоту һәм аның тирәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, мемориаль корылмаларны

сатып алу, урнаштыру, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юл челтәрен карап тоту, җиһазлар, запас частьләр сатып алу, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү),

(урам юлларына вак таш салу, вак таш белән юллардагы чокырларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау буенча башка төр эшләр);

тротуарлар ясау, ремонтлау (урам юл челтәрен карап тоту, җиһазлар, запас частьләр сатып алу, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне төзү, төзекләндерү, тоту һәм җиһазландыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, башка эш төрләре);

массакүләм ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт мәйданчыклары, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннары) һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, төзекләндерү һәм хезмәт күрсәтү өчен инвентарь, җайланмалар, кече архитектура формалары һәм техника сатып алу һәм урнаштыру, материал сатып алу, ташу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне урнаштыру, тоту, төзекләндерү һәм җиһазландыру буенча башка эш төрләре;

тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, башка эш төрләре);

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (проект-смета

документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, башка эш төрләре);

традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймаларын ремонтлау, төзү, (зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын урнаштыру, карап тоту, төзекләндерү һәм җиһазлау буенча башка төр эшләр).

3. Әлеге карарны Зур Сәрдек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зур Сәрдек авыл җирлеге башлыгы: Ф.М. Фәттахов